КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 май г.Казань № 493

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төзелергә, реконструкцияләнергә, капиталь ремонтланырга һәм (яки) төзекләндерелергә тиешле иҗтимагый инфраструктура объектлары исемлекләрен формалаштыруда катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төзелергә, реконструкцияләнергә, капиталь ремонтланырга һәм (яки) төзекләндерелергә тиешле иҗтимагый инфраструктура объектлары исемлекләрен формалаштыруда катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын (алга таба – исемлекләр, Регламент) расларга.

2. Исемлекләрне формалаштыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына аларны Регламент нигезендә формалаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Регламентка таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә торуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин